**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№1324**
**01.03.2024**

Яр Чаллы шәһәренең «Р.С. Хәмәдиев исемендәге «Тулпар» ат спорты мәктәбе» муниципаль автономияле өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 1 өлешнең 4 пункты, шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.21 пункты, Шәһәр Советының 2008 елның 19 ноябрендәге 35/7 номерлы Карары белән расланган Муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифлар билгеләү турында карарлар кабул итү тәртибе хакында нигезләмәнең 5 пункты, Башкарма комитетның 2013 елның 1 ноябрендәге 6561 номерлы Карары белән расланган Муниципаль унитар предприятиеләрнең һәм муниципаль учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифларны исәпләү тәртибе турында нигезләмә нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәренең «Р.С. Хәмәдиев исемендәге «Тулпар» ат спорты мәктәбе» муниципаль автономияле өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәренең «Р.С. Хәмәдиев исемендәге «Тулпар» балалар-яшүсмерләр ат спорты мәктәбе» муниципаль автономияле учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында» 2022 елның 1 ноябрендәге 6016 номерлы Карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе                                                                    Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2024 елның 1 мартындагы
1324 номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәренең «Р.С. Хәмәдиев исемендәге «Тулпар» ат спорты мәктәбе»
муниципаль автономияле өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан
күрсәтелә торган хезмәтләргә
тарифлар

| № т/б | Хезмәтнең исеме | Үлчәү берәмлеге | Бәясе |
|---|---|---|---|
| I. Транспорт чараларын саклау хезмәтләре | | | |
| 1. | Җиңел автомобиль | Ай/тәүлек | 1000,00/100,00 |
| 2. | Микроавтобус (3 м дан озын йөк Газеле) | Ай/тәүлек | 1200,00/150,00 |
| 3. | Трактор | Ай/тәүлек | 1300,00/150,00 |
| 4. | Йөк автомобиле ( 5,5 м дан озын йөк Газеле) | Ай/тәүлек | 1500,00/150,00 |
| 5. | Җиңел автомобиль тагылмасы (1,7 м дан 3,5 м га кадәр) | Ай/тәүлек | 1000,00/100,00 |
| 6. | Йөк автомобиле тагылмасы (3,5 м дан 8 м га кадәр) | Ай/тәүлек | 1500,00/150,00 |
| 7. | Мотоцикл (квадроцикл, самокатлар) | Ай/тәүлек | 600,00/50,00 |
| 8. | Карда йөри торган транспорт чарасы | Ай/тәүлек | 1000,00/100,00 |
| II. Ял һәм спорт өчен товарларны прокатка бирү буенча хезмәтләр | | | |
| 1. | 14 яшькә кадәрге балаларга тимераяклар | кеше/1 сәгать | 90,00 |
| 2. | 14 яшьтән зуррак балаларга, зурларга тимераяклар | кеше/1 сәгать | 120,00 |
| 3. | Тимераяклар үткенләү | 1 хезмәт | 100,00 |
| 4. | Әйберләрне саклау | 1 сәгать | 30,00 |
| III. Чаралар оештыру һәм үткәрү хезмәтләре. Хайваннарны прокатка бирү | | | |
| 1. | Спорт атына атланып йөрергә өйрәтү буенча тренер белән индивидуаль дәресләр | 1 сәгать | 1200,00 |
| 2. | «Тулпар» АСМ – «Яр буе» паркы маршруты буенча тренер ярдәмендә:<br>- спорт атына<br>- понига атланып йөрү | <br><br>1 сәгать<br>1 сәгать | <br><br>600,00<br>400,00 |
| 3. | «Тулпар» АСМ территориясендә тренер ярдәмендә:<br>- спорт атына<br>- понига атланып йөрү | <br>1 маршрут/1 урын<br>1 маршрут/1 урын | <br>400,00<br>300,00 |
| 4. | Шәһәр чараларында тренер ярдәмендә:<br>- спорт атына<br>- понига атланып йөрү | <br>1 маршрут/1 урын<br>1 маршрут/1 урын | <br>400,00<br>300,00 |
| 5. | Шәһәр чараларында тренер ярдәмендә чаналарга, фаэтонга, каретага утырып йөрү | 1 маршрут/1 урын | 300 |
| 6. | Тренер ярдәмендә тантаналы рәвештә каретага утырып йөрү | 1 чара/1 сәгать | 3000,00 |
| 7. | Атны куна кертү | Ай/тәүлек | 5000,00/200,00 |
| 8. | Манеж дәресләре хезмәте | 1 сәгать | 500,00 |
| 9. | Ат черемәсе | 1 кг | 50,00 |
| 10. | Атта фотосессия | 30 минут/1 сәгать | 1500,00/2000,00 |

*Автотранспорт чараларын саклау хезмәтләренә I, II төркем инвалидларга 50 %, хәрби хәрәкәтләр ветераннарына (тол калган хатыннарына), катнашучыларына 30% күләмендә ташлама бирелә.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева